**"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында»гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре хакында**

# БӘЯЛӘМӘ

Урыссу штб 20 ноябрь 2024 ел

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырылган (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында кире элемтә платформасының җәмәгать тавыш бирү подсистемасында урнаштырылган Татарстан Республикасы Ютазы район Советының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында" карар проекты хакында"гы 14.10.2024 елның № 26 санлы карары белән билгеләнде.

Гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә: "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты хакында.

Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы: Татарстан Республикасы Ютазы район Советы.

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны: 19.11.2024 ел, Мәскәү вакыты белән 18 сәгать 00 минутта түбәндәге адрес буенча: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Урыссу ш. т. б., Пушкин ур., 38 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының утырышлар залы.

Катнаштылар: 35 кеше.

Көн тәртибе: "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карары проекты буенча фикер алышу.

Әлеге сорау буенча чыгыш ясады: Якупов Руслан Мөгамбәр улы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының юридик бүлеге җитәкчесе, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 28.04.2020 елның № 18 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 06.10.2003 елның № 131-ФЗ санлы Федераль Законына, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында»гы 21.07.2005 елның № 97-ФЗ санлы Федераль законына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Карары проектын хупларга тәкъдим итте.

Гомуми фикер алышу нәтиҗәсендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Карары проектын исәпкә алып, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә түбәндәге карар кабул ителде:

1. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Карары проектын хупларга.

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында"гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының әлеге карары проектын Татарстан Республикасы Ютазы район Советы каравына кертергә.

Рәис: Ильясов Зәкуан Варис улы

Сәркатип: Якупов Руслан Мөгамбәр улы